**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**2024 елда Татарстан Республикасының В.Е. Алемасов исемендәге дәүләт премиясен тапшыру турында**

Татарстан Республикасының В.Е. Алемасов исемендәге дәүләт премиясен бирү комитеты тәкъдимнәрен карап тикшергәннән соң **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасының В.Е. Алемасов исемендәге дәүләт премиясен түбәндәгеләргә тапшырырга:

1) техник фәннәр кандидаты, «Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе Транспорт корылмалары институтының «Автомобиль юллары, күперләр һәм тоннельләр» кафедрасы доценты Буланов Павел Ефимовичка – аеруча нык һәм икътисадый яктан файдалы автомобиль юллары конструкцияләре төзү өчен юл-төзелеш материалларының яңа төр технологияләрен эшләүгә зур өлеш керткәне өчен;

2) техник фәннәр докторы, «А.Н. Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты – КАИ» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең «Радиофотоника һәм микродулкын технологияләре» кафедрасы мөдире, доценты Кузнецов Артем Анатольевичка – электроэнергетика объектларын һәм зур булмаган космик аппаратларны контрольдә тоту өчен радиофотон мәгълүмат-үлчәү системаларын камилләштерүгә зур өлеш керткәне өчен;

3) техник фәннәр кандидаты, «Казан дәүләт энергетика университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең «Сәнәгать предприятиеләрен электр энергиясе белән тәэмин итү» кафедрасы доценты Петров Тимур Игоревичка – электр машиналарының электр энергиясен сакчыл куллануын арттыру конструкциясен оптимальләштерүнең комплекслы ысулын өйрәнүгә зур өлеш керткәне өчен.

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** — **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ · АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2024 ел, 28 июнь
№ 494